**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**
**Боерык**

03.08.2013 Казан ш. № 21-72-57

**“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын раслау турында” 03.08.2009 ел, №21-75-86 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында” 23.07.2013 ел, №252-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын раслау турында” 03.08.2009 ел, №21-75-86 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.7.1, 23.66 статьяларын, 28.1 статьясының 1 өлешен, 28.3 һәм 28.7 статьяларын тормышка ашыру максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 6 июль, 2005 ел, №323 карары белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турында нигезләмәгә туры китереп, боерык бирәм:”;

1 пунктның 1.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15.1, 15.14-15.15.16 статьяларында, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 20 өлешендә, 19.6 һәм 19.7 статьяларында күздә тотылган хокук бозулар составы буенча:

- Татарстан Республикасы финанс министры;
- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры – министрның беренче урынбасары;
- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаменты директорының бюджет кредитларын бирүне һәм кире кайтаруны тәэмин итүче подразделение эшчәнлеген җайга салучы урынбасары;
- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаменты директорының подразделениеләрнең контрольлек-ревизия эшчәнлеген җайга салучы урынбасары;
- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының анализ һәм стратегия бүлеге начальнигы һәм бюджет кредитларын бирү һәм кире кайтару эшчәнлегенә җитәкчелек итүче урынбасары;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының оператив контрольлек бүлеге начальнигы һәм аның урынбасары;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының төбәк контрольлеге бүлеге начальнигы һәм аның урынбасары;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаменты территориаль бүлекләренең районара контрольлек-ревизия бүлекләре начальниклары.";

1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 1.3 пунктча өстәргә: "Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.27 статьясында, 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.5 статьясындагы 1 өлешендә, 19.6 һәм 19.7 статьяларында күздә тотылган хокук бозулар составлары буенча:

- Татарстан Республикасы финанс министры;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры – министрның беренче урынбасары;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаменты директорының подразделениеләрнең контрольлек-ревизия эшчәнлеген җайга салучы урынбасары;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының оператив контрольлек бүлеге начальнигы һәм аның урынбасары;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының төбәк контрольлеге бүлеге начальнигы һәм аның урынбасары.";

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15.1, 15.14-15.15.16 статьяларында, 19.5 статьясындагы 20 өлешендә күздә тотылган хокук бозулар составлары буенча:

- Татарстан Республикасы финанс министры;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры – министрның беренче урынбасары.".

2. Бу Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **Р.Р. Гайзатуллин**